КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 май г.Казань № 328

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан финанслаша торган авыл туризмын үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 сентябрь, 950 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан финанслаша торган авыл туризмын үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 сентябрь, 950 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 февраль, 136 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «грантлар» сүзен «грант» сүзенә, «финансланучы» сүзен «финанслана торган» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «грантлар» сүзен «грант» сүзенә, «финансланучы» сүзен «финанслана торган» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Федераль бюджеттан финанслаша торган авыл туризмын үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантларын бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 2 сентябрь, 950 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 16 май, 328 нче
карары редакциясендә)

# Федераль бюджеттан финанслаша торган авыл туризмын үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантын бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә кертелгән, авыл туризмын үстерү проектлары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгында (алга таба - Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Авыл туризмын үстерү проектларын конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру тәртибен раслау турында» 2022 елның 10 февралендәге 68 номерлы боерыгы белән расланган тәртиптә конкурс нигезендә сайлап алу узган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалыклардан тыш) авыл туризмын үстерү проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантын бирү шартларын һәм тәртибен билгели

Грант Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә яисә авыл агломерацияләре территорияләрендә эшчәнлек алып баручы сайлап алуда катнашучыларга бирелә.

1.2. Бу Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

эшчәнлекнең план күрсәткечләре - авыл туризмын үстерү проектына кертелә торган җитештерү һәм икътисадый күрсәткечләр, шул исәптән натураль һәм акча күрсәткечләрендә чагылган авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләме, авыл туризмы проектын гамәлгә ашыру кысаларында алынган керем күләме, сайлап алуда катнашучы авыл туризмы объектларына килүче туристларның һәм экскурсантларның планлы саны;

авыл туризмын үстерү проекты - авыл туризмы объектларын төзүгә һәм (яисә) үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота торган Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган форма буенча төзелгән документ (бизнес-план), аңа шул исәптән финанс ягыннан тәэмин итү грант акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылырга рөхсәт ителә торган чыгымнар исемлегендә каралган авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыруга чыгымнар да керә, авыл туризмын үстерү проектының биш елдан артмаган үз-үзен аклау срогын күздә тоткан финанс-

икътисадый нигезләү, аларга ирешү йөкләмәсе грант бирү турындагы килешүгә кертелә торган эшчәнлекнең план күрсәткечләре кертелә (алга таба - килешү). Авыл туризмын үстерү проектына үзгәрешләр кертү очраклары һәм тәртибе Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә;

авыл территорияләре - муниципаль район чикләрендәге гомуми территория белән берләштерелгән авыл җирлекләре яисә авыл җирлекләре һәм авылара территорияләр, шәһәр җирлекләре, муниципаль округлар, шәһәр округлары составына керә торган авыл торак пунктлары (территорияләрендә Татарстан Республикасының административ үзәкләре булган шәһәр округларыннан тыш). Авыл территорияләре исемлеге Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба - Министрлык) «Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеген һәм Татарстан Республикасының авыл агломерацияләре исемлеген раслау турында» 2020 елның 5 мартындагы 48/2-б номерлы боерыгы белән расланды;

авыл агломерацияләре – бер-берсенә тоташкан авыл территорияләре һәм (яки) авыл территорияләре белән янәшә булган шәһәр тибындагы поселоклар һәм (яки) кече шәһәрләр. Авыл агломерациясе составына керә торган һәр торак пункт территориясендә даими яшәүче халык саны 30 мең кешедән арта алмый. Бер-берсенә тоташкан авыл территорияләре дигәндә муниципаль берәмлекләрнең чиктәш чикләренә ия авыл территорияләре аңлашыла. Авыл агломерацияләре исемлеге Министрлыкның «Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеген һәм Татарстан Республикасының авыл агломерацияләре исемлеген раслау турында» 2020 елның 5 мартындагы 48/2-пр номерлы боерыгы белән расланган;»

авыл туризмын үстерү проектының үз-үзен аклау срогы - авыл туризмын үстерү проекты тарафыннан үстерелә торган чиста акча агымы суммасы аңа кертемнәр суммасыннан артып киткән вакыт.

1.3. Грант Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Авыл туризмын үстерү» төбәк проекты кысаларында бирелә.

1.4. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучы буларак тиешле финанс елына грантлар бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелде бюджет акчаларын баш бүлүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы - Министрлык.

1.5. Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба тиешенчә – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.6. Грант алучыларны сайлап алу (алга таба - сайлап алу) үткәрү ысулы - тәкъдимнәр (заявкалар) соратып алу (алга таба - заявка) - сайлап алу критерийларына һәм заявкалар керү чиратына туры килүдән чыгып, сайлап алу уздыру.

1.7. Грант алучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы муниципаль районының авыл территориясендә яисә авыл агломерациясе территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

«Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы» (ОКВЭД 2) ОК 029-2014 (КДЕС Ред.2) (алга таба - ОКВЭД) 01 «Үсемлекчелек һәм терлекчелек, аучылык һәм бу өлкәләрдә тиешле хезмәтләр күрсәтү», 03 «Балык тоту һәм балык үрчетү» класслары кодларына һәм (яки) 11.02. «Виноградтан шәраб җитештерү» төркеменә туры килә торган эшчәнлекнең төп төрен гамәлгә ашыру. Сайлап алуда катнашучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы булган очракта (авыл хуҗалыгы кулланучылар кредит кооперативыннан тыш) «Азык-төлек продуктлары җитештерү» ОКВЭД 10 бүлегенең кодларына туры килә торган эшчәнлекнең төп төре булу рөхсәт ителә;

грант алган көннән алып кимендә биш ел дәвамында авыл территориясендә яисә авыл агломерациясе территориясендә эшчәнлек башкару һәм авыл туризмын үстерү проектында каралган эшчәнлек күрсәткечләренә ирешү турында йөкләмәләр булу;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган тәртиптә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгында конкурс нигезендә сайлап алынган авыл туризмын үстерү проекты булу.

1.8. Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

1.9. Министрлыкның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

1.10. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

## II. Грант бирү шартлары

2.1. Грант грант алучыга түбәндәге шартларны исәпкә алып бирелә:

а) грант акчаларын үзләштерү срогы күрсәтелгән акчаларны алган көннән соң 18 айдан да артмый. Грант акчаларын билгеләнгән вакытта үзләштерүгә комачаулаучы җиңеп булмый торган көч килеп чыккан очракта, грант алучы гаризасы буенча грант акчаларын үзләштерү чоры Министрлык тарафыннан Министрлык билгеләгән тәртиптә алты айдан да артык булмаган вакытка озайтылырга мөмкин;

б) грант акчалары исәбеннән сатып алынган мөлкәтне алу бары тик Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән килештергәндә генә, шулай ук авыл туризмын үстерү проектында һәм грант алучы белән Министрлык арасында

төзелә торган килешүдә каралган эшчәнлекнең планлы күрсәткечләренең начараймавышарты белән генә рөхсәт ителә;

в) авыл туризмын үстерү проектында каралган грант алучының чыгымнарын финанс белән тәэмин итү дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре исәбеннән рөхсәт ителми;

г) дәүләт ярдәменең башка рәвешләре исәбеннән элек сатып алынган мөлкәтне грант исәбеннән сатып алу рөхсәт ителми;

д) грант алучылар, шулай ук грант алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю;

е) грант алучының, грант алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерүгә һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгы.

2.2. Грант грант алучыга авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыруга түбәндәге күләмдә бирелә:

3 млн. сумга кадәр (3 млн. кертеп) - авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыруга аның бәясенең кимендә 10 проценты күләмендә грант алучының үз акчаларын юнәлткәндә;

5 млн. сумга кадәр (5 млн. кертеп) - авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыруга аның бәясенең кимендә 15 проценты күләмендә грант алучының үз акчаларын юнәлткәндә;

8 млн. сумга кадәр (8 млн. кертеп) - авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыруга аның бәясенең кимендә 20 проценты күләмендә грант алучының үз акчаларын юнәлткәндә;

10 млн. сумга кадәр (10 млн. кертеп) - авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыруга аның бәясенең кимендә 25 проценты күләмендә грант алучының үз акчаларын юнәлткәндә.

Төгәл бер грант алучыга бирелә торган грант күләме, грант алучының авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән үз акчалары күләменә карап, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Әгәр грант алучыга Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы төзи торган авыл туризмын үстерү проектларын сайлап алуны оештыру һәм уздыру комиссиясе (алга таба - комиссия) карары нигезендә бирелә торган грант күләме заявкада соратылган суммадан азрак булса, грант алучы, авыл туризмы проектын гамәлгә ашыру максатларында, заявкада күрсәтелгән бюджет нигезендә тулы күләмдә өстәмә бюджеттан тыш акчалары җәлеп итәргә яки грант алудан баш тартырга хокуклы, ул бу хакта комиссия утырышы беркетмәсе (алга таба - Беркетмә) рәсми

басылып чыккан көннән алып 10 календарь көн эчендә Министрлыкка хәбәр итәргә тиеш.

Салым түләүченең өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле йөкләмәләрен үтәүдән азат итү хокукыннан файдаланучы грант алучылар өчен чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу чыгымнары суммасыннан (өстәлгән кыйммәткә салым суммасын кертеп) чыгып гамәлгә ашырыла. Грант бер тапкыр бирелә.

2.3. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарның юнәлешләре Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Агротуризм» грантын тотуның максатчан юнәлешләре исемлеген раслау турында» 2022 елның 2 мартындагы 116 номерлы боерыгы белән расланды:

1) авыл туризмы өлкәсендә хезмәт күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган урнаштыру чараларын, шул исәптән модульлеләрне, туристик күрсәтү объектларын, авыл туризмының күңел ачу инфраструктурасы объектларын, балалар күңел ачу комплексларын, прокат объектларын да кертеп, сатып алу, төзү, модернизацияләү яисә реконструкцияләү;

2) авыл туризмы өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган урнаштыру чараларын, объектларны, туристик күрсәтү объектларын, авыл туризмының күңел ачу инфраструктурасы объектларын, балалар күңел ачу комплексларын да кертеп, электр, су, газ һәм җылылык үткәргеч, шул исәптән автоном, челтәрләргә, канализация челтәрләренә тоташтыру, автоном электр, су-, газ һәм җылылык белән тәэмин итү чыганакларын төзекләндерү;

3) икътисадый эшчәнлек төрләре буенча продукциянең гомумроссия классификаторы (ОКПД 2) ОК 034-2014 (КПЕС 2008) нигезендә продукция төренең түбәндәге кодлары нигезендә туристлык объектларын, шул исәптән прокат пунктларын, туристлык күрсәтү объектларын һәм күңел ачу инфраструктурасы объектларын эксплуатацияләүне тәэмин итү максатларында туристик җиһазлар, җайланмалар һәм инвентарьлар, шул исәптән балалар күңел ачу комплексларын да кертеп, сатып алу һәм монтажлау, авыл туризмы өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган урнаштыру чараларын җиһазлау өчен җиһазлар һәм җайланмалар, техника, махсуслаштырылган транспорт сатып алу һәм монтажлау:

| | |
|---|---|
| 16.23.20.120 | Җәнлекләр, хайваннар һәм кошлар тоту өчен агач йортлар; |
| 27.11 | Электр двигательләре, генераторлар, трансформаторлар; |
| 27.51.21.121 | Универсаль кухня машиналары; |
| 28.25.12.130 | Көнкүреш кондиционерлары; |
| 28.25.13 | Суыткыч һәм туңдыргыч җиһазлары һәм җылылык насослары, көнкүреш җиһазларыннан тыш; |
| 28.29.32 | Үлчәү өчен кирәкле җайланмалар һәм кешеләрне үлчәү өчен һәм көнкүреш үлчәүләре; |
| 28.29.5 | Сәнәгать тибындагы савыт-саба юу машиналары; |
| 28.30.2 | Авыл хуҗалыгы өчен башка тракторлар; |
| 28.30.86.120 | Бакчачылык өчен башка төркемнәргә кертелмәгән җиһазлар; |

| | |
|---|---|
| 28.93.15 | Электр булмаган икмәк пешерү мичләре; ризыкны әзерләү яисә җылыту өчен сәнәгать җайланмалары; |
| 28.93.15.110 | Электр булмаган икмәк пешерү мичләре; |
| 28.93.15.120 | Сәнәгать азык әзерләү яисә җылыту өчен җиһазлар; |
| 28.93.15.121 | Стационар азык-төлек казаннары; |
| 28.93.15.122 | Кухня плитәләре; |
| 28.93.15.123 | Азык-төлек пешерү һәм кыздыру аппаратлары; |
| 28.93.15.126 | Пароконвектоматлар; |
| 28.93.15.127 | Икмәк пешерү шкафлары; |
| 28.93.15.128 | Кыздыру шкафлары; |
| 28.93.15.131 | Җылылык мармитлары; |
| 28.93.15.132 | Җылылык өстәлләре; |
| 28.93.15.133 | Кыздыру өслекләре; |
| 28.93.15.139 | Бүтән төркемнәргә кертелмәгән башка сәнәгать азык әзерләү яисә җылыту җайланмасы; |
| 28.93.17.110 | Ит, яшелчә һәм камыр эшкәртү өчен машиналар (җәмәгать туклануы предприятиеләрендә продуктларны механик эшкәртү өчен җиһазлар); |
| 28.93.17.111 | Чистарту машиналары; |
| 28.93.17.112 | Ваклау һәм турау өчен машиналар; |
| 28.93.17.113 | Басу-болгату машиналары; |
| 28.93.17.114 | Үлчәм-формаларга аеру машиналары; |
| 28.93.17.115 | Алмаштыру механизмнары комплекты белән универсаль машиналар; |
| 28.93.17.119 | Механик эшкәртү өчен башка машиналар; |
| 28.93.17.120 | Икмәк-күмәч әйберләре җитештерү өчен җиһазлар; |
| 28.99.32 | Карусельләр, таганнар, тирлар һәм башка аттракционнар; |
| 28.99.32.110 | Карусельләр; |
| 28.99.32.120 | Таганнар; |
| 29.10.3 | 10 яки аннан да күбрәк кеше йөртү өчен автотранспорт чаралары; |
| 29.10.52.110 | Карда йөри торган танспорт чаралары; |
| 29.10.52.130 | Квадроцикллар; |
| 29.10.59.280 | Транспорт чаралары - азык-төлек продуктларын ташу өчен фургоннар; |
| 29.20.22.000 | Табигатьтә яшәү яисә ял итү өчен фургоннар тибындагы тагылмалар һәм ярымтагылмалар; |
| 30.11.21 | Круиз суднолары, экскурсия судноларын һәм пассажирлар йөртү өчен шундый ук йөзү чаралары; барлык типтагы паромнар; |
| 30.12.19 | Йөрү-йөреп кайту яисә спорт судноларын; ишкәкле көймәләр, шлюпкалар һәм каноэлар; |
| 30.30.20 | Аэростатлар һәм дирижабльләр; планерлар, дельтапланнар һәм моторсыз оча торган башка аппаратлар; |
| 31.01.13 | Сәүдә предприятиеләре өчен агач җиһазлар; |
| 31.02 | Кухня җиһазлары; |

| | |
|---|---|
| 31.09.12 | Йокы бүлмәсе, аш бүлмәсе һәм кунак бүлмәсе өчен агач җиһазлар; |
| 31.09.14 | Пластмассалардан яки башка материаллардан җиһазлар (камыш, чыбык яки һинд камышы). |

Куллануда һәм эксплуатацияләүдә булган күрсәтелгән җиһазларны, җайланмалар һәм инвентарьны сатып алу рөхсәт ителми;

4) авыл туризмы өлкәсендә хезмәт күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган урнаштыру чараларына, авыл туризмының күңел ачу инфраструктурасы объектларына, шул исәптән балалар күңел ачу комплексларына, прокат объектларына якын территорияләрне төзекләндерү эшләрен башкару, шул исәптән:

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен ял итү зоналарын, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыкларын, адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнү мәйданчыкларын булдыру һәм төзекләндерү;

территорияләрне яктыртуны оештыру (биналар, төзелмәләр, корылмаларның архитектура яктырткычын кертеп, шул исәптән энергия саклый торган технологияләрне кулланып);

җәяүлеләр коммуникацияләрен оештыру, шул исәптән тротуарлар, аллеялар, велосипед юллары, сукмаклар ясау;

паркинглар урыннарын булдыру һәм төзекләндерү;

киртәләр, шул исәптән газ һәм тротуар коймалары урнаштыру (төзекләндерү);

инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү максатларында территорияне төзекләндерү;

табигый ландшафтларны һәм тарихи-мәдәни һәйкәлләрне саклап калу һәм торгызу.

Авыл туризмын үстерү проектларына кертелгән төзекләндерү элементлары һәм эш төрләре исемлеге Министрлык боерыгы белән билгеләнә.

2.4. Грант бирүнең нәтиҗәсе - грант бирү елыннан башлап биш ел дәвамында ел саен 31 декабрьгә түбәндәгеләрне тәэмин итү:

авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмен узган елгы дәрәҗәгә карата арттыру (табигый чагылышта);

авыл туризмы өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән керемнәр күләме үсеше алдагы ел дәрәҗәсенә карата кимендә биш процент;

мәгънәсе Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнә торган авыл туризмы объектларындабулган туристлар саны (берәмлек).

## III. Сайлап алуда катнашучыларга таләпләр

3.1. Сайлап алуда катнашучы заявка каралган һәм килешү төзелгән даталарга түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә

25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә индивидуаль эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

3.2. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул

исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

## IV. Сайлап алуны уздыру турында игълан булдыру һәм урнаштыру тәртибе

4.1. Сайлап алуны уздыру турында игълан Министрлык тарафыннан Министрлык “Электрон бюджет” системасында игъланны формалаштырылган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салынганнан һәм грант турындагы мәгълүматның бердәм порталында бастырып чыгарылганнан соң урнаштырыла.

4.2. Сайлап алуны уздыру турында игълан Министрлыкның «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасын, шул ук вакытта заявкаларны кабул итеп алу тәмамлану датасы сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннең иртәгесеннән 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 2.4 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 6.1 – 6.5 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

бу Тәртипнең 6.7 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 7.1 – 7.11 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

заявкаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 7.6 – 7.8 пунктлары нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган грант күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән грант күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә (җиңүчеләргә) бирелә торган грантның максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча грантны бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

конкурста катнашучыларга әлеге Тәртипнең 6.9 – 6.11 пунктлары нигезендә сайлап алуны уздыру турында игълан итүнең аңлатмаларын бирү тәртибе, мондый бирүне башлау датасы һәм тәгалләү вакыты;

сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) әлеге Тәртипнең 8.1 пункты нигезендә килешү имзаларга тиеш вакыт;

сайлап алуның җиңүчесен (җиңүчеләрен) әлеге Тәртипнең 8.3 пункты нигезендә килешү төзүдән читләшкән дип тану шартлары;

сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән соң килүче 14 календарь көннән дә соңга калмыйча бердәм порталда сайлап алу йомгакларын китерү беркетмәсен урнаштыру сроклары, шулай ук “Интернет” челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты).

## V. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

5.1. Бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында Министрлык тарафыннан игълан урнаштыру конкурста катнашучыларның заявкаларын бирү срогы тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

5.2. Сайлап алуны гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә “Электрон бюджет” системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат туплана.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кире алу тора.

5.3. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне юкка чыгару турында мәгълүмат бирәләр.

5.4. Сайлап алу аны гамәлдән чыгару турындагы игълан бердәм порталда урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

5.5. Әлеге Тәртипнең 5.1 пункты нигезендә сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) белән килешү төзелгәнче Министрлык Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.

## VI. Заявкаларны формалаштыру һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирү тәртибе

6.1. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгында авыл туризмын үстерү проектын конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган авыл туризмын үстерү проектларын конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру тәртибенең 7 пунктындагы 5 - 13 пунктчаларында күрсәтелгән исемлек нигезендә җибәрелгән заявка документлары;

заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән, ОКВЭД 01 «Үсемлекчелек һәм терлекчелек, аучылык һәм бу өлкәләрдә тиешле хезмәтләр күрсәтү», 03 «Балык тоту һәм балык үрчетү» һәм (яисә) 11.02 «Виноградтан шәраб җитештерү» төркеме классының кодларына туры килә торган эшчәнлекнең төп төре булуын раслый торган, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтәләр яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (сайлауда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

грант алган көннән алып кимендә биш ел дәвамында авыл территориясендә яисә авыл агломерациясе территориясендә эшчәнлек башкару һәм авыл туризмын үстерү проектында каралган эшчәнлек күрсәткечләренә ирешү турында йөкләмәләр;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган тәртиптә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгында конкурс нигезендә сайлап алынган авыл туризмын үстерү проекты.

6.2. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

6.3. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

6.4. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны

һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

Заявкага кертелгән фото- һәм видеоматериалларда югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы сурәт булырга тиеш.

6.5. Сайлап алуда катнашучының заявка бирү датасы булып заявкага “Электрон бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

6.6. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме (юридик затлар өчен);

индивидуаль эшкуарл фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры (юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар өчен);

салым түләүченең идентификация номеры;

салым органында исәпкә кую датасы (физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшкуарлар өчен);

салым органында исәпкә куелу датасы һәм коды (юридик затлар өчен);

физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәве датасы;

юридик зат адресы, теркәлү адресы (физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшкуарлар өчен);

элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

юридик зат җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

сайлап алуда катнашучы оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә (юридик затлар өчен) яисә индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестры белешмәләре нигезендә (индивидуаль эшкуарлар өчен) гамәлгә ашырырга хокуклы төп һәм өстәмә эшчәнлек төрләре исемлеге;

грантны күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) документлар әйләнеше процессында сайлап алуны уздырганда тапшырыла торган мәгълүмат һәм документлар:

«Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган грантны сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

«Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны раслау (физик затлар өчен);

г) сайлап алуда катнашучы тәкъдим итә торган әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе, сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә билгеләнгән максималь (минималь) күләмнән югарырак (түбәнрәк) була алмаган грант күләмен сайлап алуда катнашучы сораган өлешнең әһәмияте;

д) сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән һәр сайлап алу критериесе буенча мәгълүмат.

6.7. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

6.8. Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алу әлеге Тәртипнең 6.1 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучының заявкасын төзүнең шундый ук тәртибендә сайлап алуда катнашучы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.9. Бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән башлап, сайлауның теләсә кайсы катнашучысы, сайлау тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча «Электрон бюджет» системасында тиешле гарызнамә төзү юлы белән сайлап алуны үткәрү турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында Министрлыкка иң күбе биш гарызнамә җибәрергә хокуклы.

6.10. Министрлык әлеге Тәртипнең 6.9 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату күрсәтелгән белдерүдә булган мәгълүматның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

6.11. «Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге Тәртипнең 6.10 пункты нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

## VII. Заявкаларны карау тәртибе, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү

7.1. Сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында, сайлап алуда катнашучылар тапшырган заявкаларны карау өчен аларга Министрлык керү мөмкинлеге ачыла. Заявкаларны карау «Электрон бюджет» системасында заявкаларны карау өчен аларга Министрлык керү мөмкинлеге ачылган көннән соң 15 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

7.2. «Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганчы бер дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында сайлауда катнашучыларга бирелгән заявкаларга керү ачыла.

7.3. Министрлык сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән заявкаларны сайлап алуда катнашучыларга

керү мөмкинлеге алганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме (юридик затлар өчен) яисә фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшкуарлар өчен);

г) юридик зат адресы, теркәлү адресы (физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшкуарлар өчен);

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган грант күләме.

7.4. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

7.5. Әгәр ул сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаганда, заявка дөрес дип танылa.

Заявканың сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карарлар заявка составында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны сайлап алу нәтиҗәләрен тикшерү көненә Министрлык тарафыннан кабул ителә.

7.6. Гариза әлеге Тәртипнең 7.7 пунктында каралган заявканы кире кагу өчен нигезләр булган очракта, кире кагыла.

7.7. Заявканы карау стадиясендә заявканы кире кагу өчен нигезләр түбәндәгеләр тора:

а) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

в) тапшырылган документларның һәм (яисә) заявкаларның сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

г) заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

д) сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

7.8. Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карау срогы тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан заявкаларны карау беркетмәсе әзерләнә, ул кергән һәм каралган заявкаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук сайлап алуның һәр катнашучысы буенча аның заявкасын тиешле дип тану яисә, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә ала.

7.9. Заявкаларны карау беркетмәсе заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле

электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

7.10. Сайлау түбәндәге очракларда булмаган дип танылa:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кире кагылган.

7.11. Кергән заявкаларны тәртипкә салу аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

7.12. Сайлап алуда җиңүче дип Министрлык тарафыннан оештырылган кергән гаризаларны ранжировкалау нәтиҗәләре буенча рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучылар танылa.

7.13. Сайлап алуны төгәлләү һәм җиңүчеләрне ачыклау максатларында сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм “Электрон бюджет” системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куйган көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла, һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган грант алучының (грант алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган грантның күләме.

## VIII. Килешүләр төзү һәм грант күчерү тәртибе

8.1. Министрлык сайлап алу нәтиҗәләре буенча грант алучы (грант алучылар) белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә грант алучы (грант алучылар) билгеләнгәннән соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча килешү төзи.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

Министрлык, кирәк булганда, грант алучы белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

8.2. Юридик зат булган грант алучыны кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, килешүгә, хокук варисы булган юридик затны килешүдә күрсәтеп, мәҗбүри рәвештә затны алмаштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

Юридик зат булган грант алучыны бүленү, бүлеп бирү рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, шулай ук юридик зат булган грант алучы юкка чыгарылганда, яки индивидуаль эшкуар булган грант алучының эшчәнлеге туктатылганда (Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлек алып баручы индивидуаль эшкуардан тыш), килешү берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә һәм, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган, грант алучы тарафыннан үтәлмәгән йөкләмәләр турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне башкару һәм грантның файдаланылмаган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кайтару турында акт төзеп фомалаштырыла.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар булган, үз хокукларын башка гражданга «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә тапшыра торган грант алучының эшчәнлеге туктатылганда килешүгә, хокук варисы булган башка зат килешүендә якларны күрсәтеп, затны үзгәртү өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

8.3. Сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән срокларда грант алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, грант алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

8.4. Министрлык килешүләр төзүне төгәлләү срогын сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча грант алучыларга грантлар бирү турында карар кабул итә, ул Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

грант алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

8.5. Министрлык грант бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан грант алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

## IX. Грантлар бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру хисабын бирү тәртибе

9.1. Грант алучы «Электрон бюджет» системасында килешүләр өчен Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формалар буенча хисаплар бирә:

финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап - грант үзләштерүнең билгеләнгән срогы дәвамында хисап кварталыннан соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

грант бирү нәтиҗәләренең мәгънәсенә ирешү турында хисап - квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, еллык хисап - грант бирү елыннан соңгы елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча биш ел дәвамында биреләчәк.

9.2. Килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешүне грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыручы вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

Микроэшмәкәрлек субъектлары булган грант алучылар өчен «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә грант бирү нәтиҗәләренә ирешү мониторингы елга бер тапкыр уздырыла.

9.3. Министрлык әлеге Тәртипнең 9.1 пунктында күрсәтелгән хисапларны күрсәтелгән хисаплар бирелгән көннән алып 60 эш көненнән артмаган вакытта тикшерә.

Министрлык грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, үтәвен тикшерә. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

9.4. Бирелгән грантлар грант алучының әлеге Тәртип һәм килешү тарафыннан грант биргәндә билгеләнгән тәртип һәм шартларны бозуы, хисаплылыкны тапшырмау, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, шулай ук грант алучының килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәве очракларында бюджет законнары нигезендә Министрлыктан тиешле таләп алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keремена кире кайтарылырга тиеш.

9.5. Килешүдә каралган очракларда грант алган көннән соң 18 ай эчендә файдаланылмаган грант өлеше грант алучы тарафыннан грантны үзләштерүнең күрсәтелгән срогы тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кайтарылырга тиеш.

9.6. Әлеге Тәртипнең 9.4 һәм 9.5 пунктларында күрсәтелгән акчаның Татарстан Республикасы бюджеты керемена ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Министрлык тарафыннан мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

9.7. Грант алучыны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырган очракта, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указының 2 пункты нигезендә (алга таба - хәрби хезмәткә чакыру) Министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

авыл туризмын үстерү проектын, грант акчаларыннан тулысынча файдаланган очракта, тәмамланган дип тану, ә грант алучыга карата, хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле рәвештә, эшчәнлекне шәхси эшкуар буларак туктатуны дәүләт теркәвенә алу яисә крестьян (фермер) хуҗалыгын туктатуны дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылган. Шул ук вакытта грант алучы эшчәнлекнең планлаштырылган күрсәткечләренә ирешмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә;

грант акчалары файдаланылмаган яисә тулысынча файдаланылмаган очракта, грант акчаларының Татарстан Республикасы бюджетына файдаланылмаган күләмдә кире кайтарылуын тәэмин итү, ә грант алучыга карата, хәрби хезмәткә чакыруга бәйле рәвештә, шәхси эшкуар буларак эшчәнлекне туктатуны дәүләт теркәвенә алу яисә крестьян (фермер) хуҗалыгын туктатуны дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылган. Шул ук вакытта авыл туризмын үстерү проекты төгәлләнгән дип танала, ә грант алучы эшчәнлекнең планлаштырылган күрсәткечләренә җитмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән карарлар грант алучының гаризасы буенча Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыруны раслый торган документ биргәндә һәм (яисә) Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясеннән яисә грант алучы хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны мобилизацияләү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) чакырылыш комиссиясеннән алынган белешмәләр нигезендә Министрлык тарафыннан кабул ителә. Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән карарларның күчермәләре тиешле карар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына җибәрелә.

Грант алучы крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгын хәрби хезмәткә чакырылган очракта, авыл туризмын үстерү проектын гамәлгә ашыру барышында әлеге крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзаларының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аның алмашынуы рөхсәт ителә, бу грант алучы буларак крестьян (фермер) хуҗалыгы статусын үзгәртүгә (туктатуга) китерми. Шул ук вакытта Министрлык мондый крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгын килешүдә алмаштыра, ә крестьян (фермер) хуҗалыгының яңа башлыгы күрсәтелгән килешү нигезендә авыл туризмын үстерү проектын алга таба гамәлгә ашыра.

---